**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында гражданнар җыены карары**

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алу);

- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (чүп үләннәргә каршы көрәш, зират территориясендә тротуар төзү, бензопила сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасы өчен насослар сатып алу);

- Күл Черкене авылындагы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны чокырларга ремонтлау).

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы __________ М.К.Истиев

Гражданнар җыены секретаре __________ И.Р.Гибадуллина